ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның $2^1$ өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 – 5 пунктлар өстәргә:

«3) «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләргә, килешүләргә таянып, гидротехник корылмалар булдыруны, төзүне, эксплуатацияләүне, реконструкцияләүне, модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар – плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар ителә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; суднокүтәргечләргә; су басулардан, сусаклагычлар ярларын, елгаларның ярларын һәм аларның үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда

урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата;

4) оешмалар – Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы яисә «Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чиге булган җир кишәрлекләрендә төзелгән мөлкәткә карата;

5) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә аренда шартнамәләренә таянып бирелгән җир кишәрлекләрендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң булдырыла торган гидротехник корылмалар төзүне һәм аннан соңгы эксплуатацияләүне үз һәм (яисә) заем акчалары исәбеннән гамәлгә ашыручы оешмалар – плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар ителә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; суднокүтәргечләргә; су басулардан, сусаклагычлар ярларын, елгаларның ярларын һәм аларның үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата.»;

2) 5 статьяда:

а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) 2022 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 11 – 13 пунктларын;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) 2023 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешенең 8 пунктын.».

**2 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 декабрендәге 102 -ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендәге «б» пунктчасын төшереп калдырырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«2 статья**

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясы 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 18 июнь
№ 40-ТРЗ